

Салих Хөсәенов

# Тормыш баскычлары

16+

Салих Хусаинов

# Тормыш баскычлары

«ЛитРес: Самиздат»

2018

**Хусаинов С.**

Тормыш баскычлары / С. Хусаинов — «ЛитРес: Самиздат», 2018

Разные очерки из истории жизни школы, рассказы из жизни села на татарском языке.

© Хусаинов С., 2018
© ЛитРес: Самиздат, 2018

Сикентэле гомер сукмагы.
Гомер сукмаклары дилэр
Була икэн чикле – киртэле
Шул чиклэрне уза-уза
Яшисе иде эле.

Хормэтле редакторымның – Абдрахманов Рэхим Гарип улының «Куңел дэфтэреннэн».

Мин 1927 елның 1 июлендә Татарстан республикасының Тәтеш районы Олы Тархан авылында туганмын. Әнинең эйтүе буенча: «Бу көн җэйнең иң матур, иң аяз, тыныч көне иде. Шуңа, улым, сиңа матур, шатлыклы, бэхетле тормышлар телим».

Һэр ана узенең баласына, тэбигать мизгеллэренә туры китереп, бәхетле тормышлар тели.

Бала чаклар һәр кайсыбызның уйнап-көлеп шатланып, пыр-туздырып йоргэн коннэре инде. Бала чагымда урамыбыздагы күрше малайлары белән төрле-төрле уеннар уйный идек. Әмма миңа иркенләп озак уйнарга туры килмәде. Бакча эшләреннән башка, хуҗалыкта сарык, кәҗә сыер асрый идек. Яшелчәләрнең чубен утарга, хайваннарның asларын әрчергә, ашатырга-эчерергә булыша идем. Кышын кар да чистартасы бар иде эле.

Эти-эниемнен тугыз баласы булган: Кадир, Мингалим, Хэбир, Мэгъбурә, Фәһимә, Хэммэт, Фәридә, Салих(мин), Суфия. Этием яшли улгэн. Мина 9 яшь кенэ тулган иде эле. Хэбир белэн Мэгьбурә бала чакта улгэннэр. Ике абыем, Кадир белэн Мингалим, уз семьяларын корып, аерым яшәделәр. Бәхетсезгә, вакытсыз дигэндэй, Ватан сугышы башланды. Оч абыем һэм ике җизнэм беренче коннэрдэн үк илебезне фашистлардан сакларга озатылды.

Хэммэт абыем бер еллар иртэрэк урта мэктэпне тэмамлап башлангач классы укытучысы итеп билгеләнгэч тэ бер-ике ай да эшлэмэгэндер, хэрби гаскэрлэрне хэзерлэү курсына алдылар. Ул кече лейтенант дәрәҗәсе алып сугышка катнашты. Авылыбызга бер-бер артлы кара печэтле – кайгы хэбэрлэр килэ башлады. Шундый кайгылы хэбэрлэр безне урап үтмэде. Ике абыем һэм бер җизнэм сугыш кырында ятып калдылар. Э Хэммэт абыем бер күзен алдырды. Ул эле госпитальдан бераз сэлэмэтлэнеп чыккач та хэрби эшен дэвам иткэн. Өлкэн лейтенант дэрэҗэсендэ яшь солдатларны сугышка хэзерлэгэн. Ул авылыбызга 1947 елда гына кайтты.

Сугыш елларында һэм ары да безнең кебеклэрнең яшәүлэрен күп яздылар. Безнең яшьлек елларыбыз да шулар кебек үк. Ашарга юк, өскэ кияргэ – эни мескен ничек иске-поскылар табып, кышларын катып үлмэслек кенэ итэ алган. Аякларда чабата. Аяклар туңуга чыдар хэллэр юк иде. Язын чыккач пычракка бата-чума эчерек бэрэңге эзли идек (ярый эле бер пешерерлек таба алсаң). Читэн буйларындагы кечеткэннэр ашап бетерелде. Урманга барып зэрдэ һэм башка ашарга яраклы үлэннэр табып кайта идек. Аннары, авылдан 10–15 чакрым ерактагы, Идел буендагы болынга барып җуа(дикий лук) җыеп күтэрэ алган кадэр, элсерэп, хэлдэн таеп кайта идек. Кышларын салам ягып өйне бераз җылыта идек. Өйдэ салкын, мэктэптэ салкын, өске киемнэрне салу юк. Өстэвенэ эле язарга дэфтэре дэ, укырга китаплары юк. Укытучыларыбыз алдагы елда 10 класс бетергэннэр, җэисэ сугыштан гэриплэнеп кайткан, бераз белемле солдатлар. Кайда инде белемле уку. Укулар 1 сенябрьдэ, хэттэ октябрь урталарына кадэр соңга калып башлана. Без – укучыларны көзге ашамлыкларны җыярга җибэрэлэр иде. Мин үзем дэ 10 классны тэмамлагач 1949 елга кадэр колхозда эшлэдем. Урагын да урдым, болында печэнен дэ чаптым, үз сыерыбызны җигеп килтэсен дэ ташыдым. 1949 елда абыем белэн Тэтеш педучилищесында экстерный укып укытучы булдык. Икенче елны Казан педагог институтына керү өчен экзамен бирдек. 1949 елны мине Бакырчы җидееллык мэктэбенэ (ул елларда җидееллыклар иде) өченче класска укытучы итеп билгелэделэр. Бер айлар укыткач та Сөендек җидееллык мэктэбенэ физика-математика укытучысы итеп билгелэделэр. Мин анда ике ел эшлэдем. Шуннан Башчы мэктэбенэ күчерделэр. Анда дүрт ел эшлэгэч Олы Тархан

урта мәктәбенә кайтып эшләдем. Хезмәт стажем 45 ел булды. Эш белән бергә укуымны Казан педагог институтында читтән торып дәвам иттем.

Минем тормышымда кискен үзгәреш булып алды. Куйбышев гидростанциясе төзү еллары. Олы абыемның малае, Хөсәинов Хәмзә, Идел яр буйларындагы агачларны чистартуда катнаша. Ул эшләгән көннәрен тыңлаганнан соң мин «Яшь Сталинчы» гәҗитәсенә мәкалә язып җибәргән идем. Шуны гәҗиттә укыгач, әйтерсең лә миңа яңа канат бәреп чыкты. Мин бик тә шатландым. аннары тагын, тагын яза башладым. Редакөия миңа үзләренең планнарын җибәрә башладылар. Бу елларда Олы Тархан район үзәге иде әле (соңыннан гына, 1960 еллар тирәсендә генә Тәтеш районына куштылар). Шул елларда авылыбызда «Социализм байрагы» редакциясе барлыкка килде. Редакторы Гәлләмов Вәли иде. Бу гәҗитә битләрендә дә минем язулар көн күрде. Вәли абый әледән-әле яңа темалар бирә иде. Бик кискен, тәнкыйть материалларны, фельетоннарны «псевдоним» белән язарга тәкъдим итте. Юк-юк та үзеңне дә явыз ниятле кешеләрдән сакларга кирәк диде.

Язган материалларымны өлкә гәҗитәләренә дә, «Чаян» журналына да һәм башка редакцияләргә дә юлладым. Читтән торып укыгач редакциядә мин еш була идем.

1958 елның август аенда миңа СССР журналистлар эгъзасы (член союза журналистов СССР) итеп кабул иттеләр. Ике-өч мәртәбә Татарстан журналистлар съездында, бер мәртәбә «Яшь язучылар» съездында булырга туры килде.

Укытучылык хезмәтендә дә зур тырышлык куеп эшләдем. Верховный Совет карары белән Тәтеш районы буенча беренчеләрдән булып «Өлкән укытучы» дәрәҗәсе бирделәр. Ә биш елдан соң аттестация үткәрделәр һәм «Укытучы-методист» дәрәҗәсенә күтәрделәр.

Җәмгыять эшләре дә минем җилкәдә җитәрлек иде. Мәктәптә күп еллар профком җитәкчесе, аннан тыш биш-алтыдан да ким түгел. Мәктәбебездә ул елларын 100–140 профсоюз члены исәптә тора иде.

Тормыш иптәшем, Язилә, белән 60 ел бергә тату яшәдек. Ул 40 ел авылыбызда табиб булып эшләде. Өч бала үстердек. Олы кызыбыз, Наилә, әнисе юлыннан китте, табиб булып эшли.

Улыбыз, Айдар, мәктәпне алтын медальга бетереп КАИны бетерде. 1986 елда студентлар төркеме белән Чернобыль атом станциясының фаҗигасын бетерүдә катнашты. Шул ук елны Хабаровск шәһәренә хәрби хезмәткә китте. «Ракетные войска» да хезмәт итте. Капитан дәрәҗәсендә Ульян шәһәренә кайтып микроэлектрон институтына эшкә урнашты.

Башта сиздермичә генә торган радиация нуры үзеннән үзе көчәеп (1964–2006) 2006 елны фаҗигале үлем белән арабыздан китте.

Кече кызыбыз, Айгөл, тәрбияче хезмәтен сайлады. Казан шәһәренең Совет районының физик тәрбия бирүче инструкторларның методик оешма җитәкчесе.

Соңгы 20 елларда эшләүче мәктәп директоры (заслуженный учитель Татарстана, затем России) Шагаев Расих Инталович минем онык Азатны күргәч тә: «Синең бабаң кебек физика укытучысы безнең мәктәптә булмады да, хәзер дә юк, булачак та түгел» – дип мине мактаган. «Син дә шулай бабаң кебек бул» – дип әйтүе булгандыр.

Куз йомганчы тормышнын 90 елы узды да китте.

**Авылым тагын да ямьләнсен өчен**

Яз. Кояш көннән-көн кыздыра, көннән-көн табигать матурая, ямьләнә. Менә тиздән агачлар яфрак ярыр, авыл яшеллеккә төренер.

Шул чак ерак-ерактан, калкурак бер урыннан авыл өстенә карыйсың да, сокланып туя алмыйсың. Нинди матур син, минем туган авылым, дип рухланып, дәртләнеп куясың. Кайчан гына әле безнең Олы Тархан салам түбәле, ярым җимерек бер авыл иде. Патша заманыннан калган күзгә күренердәй калай түбәле дүрт-биш йорт бар иде. Алары да авылның байлары,

муллаларныкы булган. Авыл халкы, байларга хезмәт итеп, ачлы-туклы гомер кичергән. Шуның кадәр зур авылда ни больница, ни мәктәп булмаган. Ә хәзер хәл бөтенләй үзгә. Авылда зур больница, урта мәктәп бар. Җитмешләп югары белемле укытучы, медицина работнигы эшли.

Авыл елдан-ел үзгәрә, төзекләнә бара. Шушы соңгы ун ел эчендә генә дә ике йөздән артык хуҗалык, менә дигән өйләр салып, түбәсен калай яки шифер белән яптырды. Йөзләгән хуҗалыкта мотоцикл, велосипед бар. Һәр өйдә электр уты балкый, радио сөйли. Бер ел эчендә генә дә 15 хуҗалык телевизор алды. Шуларны күргәч, ничек горурланмыйсың да, ничек шатланмыйсың.

Биш-алты ел да үтмәс, туган авылым да төзекләнеп, тагын да матураеп, гөлбакча эчендә калыр. Шул киләчәкне күз аллыйсың да, шатланып туя алмыйсың.

Авыл ямь-яшел чирәм белән дә капланса, нинди ямьле булыр иде. Ләкин кайбер гамьсез тракторчылар һәм шоферлар, теләсә кайда юл салып, урамнарны таптап, изеп бетерәләр. Бу башбаштаклыкка чик куелсын иде инде.

Авылның төзеклеге һәм матурлыгына кайбер җитәкче иптәшләрнең битараф каравын да әйтми мөмкин түгел. Кайчандыр безнең бабаларыбыз авыл эчендәге чокыр-чакырларны һәм сазлыкларны күмеп тигезләгәннәр, бакча утыртканнар, юл салганнар. Бу хакта хәзер уйлаган кеше дә юк. Киресенчә, авыл уртасында коточкыч чокыр, сазлыкларны күмеп тигезләгәннәр, бакча утыртканнар, юл салганнар. Бу хакта хакта хәзер уйлаган кеше дә юк. Киресенчә, авыл уртасында коточкыч чокыр, сазлыклар барлыкка килүгә юл куела.

Авылның төзеклеге һәм матурлыгы өчен көрәш һәр кешенең изге бурычы. Әгәр һәр кеше бу мөкатдәс эшне намус белән үтәсә, елның елында өй алдына агач утыртса, авылыбыз киләчәктә тагын да яшелрәк, тагын да матуррак булачак.

### Кышка хәзерлек кайчан тәмамлана

Беренче кар төшү белән «Алга» колхозының 6нчы бригадасы кышка хәзерләнергә керешә. Бригаданың яңа җитәкчесе Хатыйп Әхмәдиев ашыгыч рәвештә ункешедән төзүчеләр бригадасы оештырды. Алар бик кыйналмыйча гына эшне башлап та җибәрделәр.

Тизрәк кыймылдагыз инде, егетләр, тизрәк, – дип дәртләндерде аларны бригадир. – Ачы январь салкыннары башланганчы ферманы кышка хәзерләп бетерик.

Әмма һәр көн диярлек тоткарлык чыгып кына тора. Өстәвенә, үч иткәндәй, әле тег, әле бу төзү материаллары җитешмәде. Хатыйп әле бәрелде, бире сугылды, ашавы бетте, йокысы качты, ә материал барыбер табылмады. Үзенә кагылса, халык әйтмешли, чананы җәен әзерләп куяр иде дә, әмма Хатыйп җәен башка эштә иде шул. Ә хәзер кемнеңдер селкенмәве аркасында, аңарга янарга-көяргә туры килә.

Ягез инде, егетләр, шушы абзар ишеген булса да ясый торыгыз, – дип ялварды ул төзүчеләргә.

Нәрсә белән ясыйлар соң аны, иптәш бригадир, – диештеләр төзүчеләр.

Ничек нәрсә белән, билгеле такта белән.

Ә такта кайда?

Соң инде, егетләр, тактага да аптырап торсыз. Әнә ич пилорам, фермадан йөз метр да юк. Адыгыз да килегез шуннан.

Төзүчеләр бер-берсенә карашып, җилкәләрен җыердылар. бригадир кулын селтәде дә, тиз генә атын җиктереп, пилорамга юыртты.

Нәрсә, син, ферманы кышка хәзерләгәнне белмисеңме әллә? – дип кычкырып салды мастерга. – Нигә төзүчеләргә такта бирмисең?

Харис Солтанов күңелсез чырай беән бригадирга карап алды. Аннары авызындагы тәмәкесен читкә атып, ачу белән мотор ручкасын бора башлады. Тирләп-пешеп бетте.

Күтәрелде, маңгаендагы тирен сөртеп, агачлар өстенә барып утырды да:

Менә күр, кабыза алмыйм, янында атна артык җәфаланам инде, – диде Харис һәм тагын тәмәкесен кабызып җибәрде.

Колхозыбызның менә дигән механиклары булганда нигә үзеңә җәфаланырга. Барыгыз, тизрәк чакырыгыз үзләрен.

Механикларны эзләргә киттеләр, колхозның дан казанган механиклары килеп тә җиттеләр. Мондый гына түгел, әллә нинди катлаулы двигательләрне төзәтеп йөрүче бу осталар, моторга карап, син дә карышасың тагын, хәсрәт, дигәндәй, елмаешып алдылар һәм бик иркенләп кенә тәмәке көйрәттеләр.

Торып ансын-монсын караган булдылар, яле, мин сине дип, ручканы бора башладылар. Ә моторның моңа гына исе китмәде. Шуннан соң аның болтын-болтка сүтеп ташладылар..җыйдылар. тагын бордылар. Ә моторның моңа да исе китмәде. Тагын сүттеләр, тагын җыйдылар. Ә мотор, үч иткәндәй, дәшми-тынмый утыра иде.

Ә-ә-ә, егетләр, белдем серен, – дип кулын-кулга сугып куйды мезаникларның берсе, иң өлкәне, иң олысы.

Үзебездә җылы пальто булгач, исебез дә китми. Ә моторны туңмый дип беләсез ахры. Хәзер җылытабыз үзен. Айнар су кирәк. Тиз булыгыз! Аның шулай диюе булды, фермага кайнар суга чаптылар. Ул да түгел ферма кызлары, чиләкләренә пар бөркелеп торган су тутырып, пилорамга агылдылар.

Хәзер карыша алмассың, – дип сөйләнә-сөйләнә, моторист радиаторга кайнар су салды. – Яле, тагын койрыгыңны борып карыйк.

Бордылар. Иплән торып бордылар. Харисның хәле беткәс, механиклар чиратка басты. Ә мотор «Нигә соң сез мине шул кадәр тинретәсәсез» дигән сыман, пыфылдап та карамады.

Ә-ә-ә, болай икән, белдем серен, – дип куөды икенче механик та, кулларын угалап. – Менә хәзер карыша алмас. Артык туңганга кабынмый ул, егетләр. Ягулык багын да җылытырга кирәк.

Механик шулай диюе булды. Бензин сибеп, ягулык багына ут төрттеләр. Ут җылытса, җылыта икән ул. Бактагы ягулык кына түгел, бөтен сарай эче дә дөрли башлады. Мехниклар үзләре дә чак качып котылдылар.

Бригадир үзе дә, ачудан кара янып, кулын селтәде дә фермага, салкыннан калтыраган маллары янына олакты.

Бу вакыйга инде онытылып, такта булмау сәбәпле ферманы кышка хәзерләү дә бөтенләйгә туктатылып, тәмам җәзасын алган моторны металлоломга тапшырырга торганда, пилорамга ферма мотористы Хәммәт Ситров килеп юлыкты.

Эх, мескен, мескен, – дип куйды Ситров, тәмам эштән чыккан моторга текәлеп, ни булды сиңа?

Ул мотор тирәли бер әйләнеп чыкты, икенче әйләнде. Җаны түзмәде, үзенең дә аны боргалап карыйсы килде. Башта ул бик яхшы иттереп моторны корымнан чистартты, аннары гайкаларны борып, ниндидер кисәген сүтеп алды. Аның карашы ягулык насосындагы бе детальгә төбәлде.

Ә, менә синең авыруың кайда булган икән, хәзер, хәзер мин үзеңне дәвалыйм, – дип сөйләнә-сөйләнә, ягулык насосын да сүтте. Фильтрларын алыш-биреш иттерде: берсен алды, икенчесен куйды. Аннары моторны борып җибәре. Ә мотор, бер дә карышып тормыйча, гөрелдәп эшли башлады.

Мотор тавышын ишетеп, бригадир да чабып килеп җитте.

Эх, Хәммәт абый, – диде ул артык шатланып. – Безнең механиклар эшли алмаганны үтәдең түгелме соң… Бер бәла җилкәдән төште!

Моторы яхшы эшләсә дә, мотористлары артык кабаланмый гына такта ярдыра башладылар.

Ну, егетләр, – дип елмайды бригадир төзүчеләр алдына килеп. – ферманы кайчан кышка хәзерләп бтеәбез?

Төгәл әйтүе кыен, – дип куйды берсе. – Шушындый темп белән барсак, мөгаен, язга кадәр бетерербез.

**Бер кыз килде Тарханга…**

Галия Николаевна Мукина бүген чиксез дулкыланды. Эшкә китәр алдыннан ул көзге алдына басып төзәтенде. Зифа буйлы, мөләем карашлы бу кызның коңгыр күзләре шатлык белән балкый. Күңеле каядыр омтыла, ашкына иде аның. Олы Тархан участок больницасына ул очкан коштай килеп җитте.

Баш врач кабинетының бусагасын атлап кергәндә аның дулкынлануы тагын да арта төште, йөрәге ешрак тибә башлады.

Тыңлыйм сезне, – диде Иван Николаевич Чемезов, алсу йөзле кызга ачык чырай күрсәтеп.

Баш врачның ягымлы карашын күргәч, кыз бераз батырая төште һәм үзенең бирегә теш техникы итеп җибәрелүен әйтте.

Иван Николаевич, тирән уйга бирелгәндәй, кулын яңагына куйды. Башта врачның йөзендә ниндидер үзгәреш һәм уңайсызлану чагылып китте. Аннары ул урыныннан әкрен генә торып, кызны үзе белән ияртеп чыкты.

Амбулаториядәге кечкенә генә бер бүлмәгә үттеләр. Иван Николаевич кулы белән ишарә ясап:

Менә шушында эшләрсез, – диде. Кыз бүлмәгә күз йөртеп чыкты, аннары:

Ә эш кораллары, материаллар? – дип куйды. Баш врач, иңбашлары җыерып, кулларын җәйде һәм:

Хәзергә бернәрсәбез дә юк шул әле, – диде.

Иван Николаевич чыгып киткәч, кыз бүлмәдә беравык аптырап басып калды. Ул болай булыр дип һич тә күз алдына китермәгән иде. Төрле эш кораллары белән җиһазландырылган иркен зур бүлмәдә эшләрмен дип хыялланган иде.

Теләсә, бөтен шартлары тудырылган шәһәр больницасында да кала ала иде бит. Ләкин ул кая тиеш тапсалар, шунда җибәрүләрен үтенде.

Кинәт Галина, уянып киткәндәй, тирән сулыш алды һәм киң маңгаена төшкән коңгырт чәчләрен төзәтеп куйд. «Нәрсә мин жебеп калдым соң әле. Барысы да әзер булган җирдә кем дә эшли аны. Булмаганны булдыру, көрәшү һәм табу. Менә минем бурычым нинди булырга тиеш», – дип фикер йөртте ул.

Яшь техник, тиз-тиз атлап, урамга чыкты. Аның күңелендә ниндидер өмет чагылгандай булды. Шул өмет белән ул больницаның хуҗалык мөдире Ильясов янына китте.

Суыру шкафы юк микән households? – диде ул, Ильясовка текәлеп.

Андый нәрсәнең булганы да юк шул, – сеңелкәй.

Кулдан булса да ясатыр торырга туры килә инде, яңасын сатып алганчы ярап торыр.

Безнең кайгы анда гына түгел шул әле, сеңелкәй…

Кыз баш врач бүлмәсенә яңадан керде.

Иван Николаевич Ильясовны чакыртып алды:

Галина Николаевна нәрсә сораса, шуны үтәгез, бүгеннән үк суыру шкафын ясарга заказ бирегез.

Ильясов чыгып киткәч, кыз:

Минем Сезгә тагын бер үтенечем бар, Иван Николаевич, – дип куйды.

Сөйләгез, тыңлыйм.

Бездә коронка да, теш тә, хәтта балавыз кебек материаллар да юк икән, – дип тезеп китте Галина Николаевна. – Әгәр без аларны тиз генә Казаннан алдыртсак?

Дөрес фикер бу, Галина Николаевна, – дип, хуплады башврач. – анда Сезнең үзегезгә бару яхшырак булыр.

Икенче көнне үк ул Казанга китте.

Казанда күп кыенлыкларны үтәргә кирәк булды аңа. Әмма тырышлык бушка китмәде. Әле бер, әле икенче урыннан җиһазлар булдырып, материаллар табыштырып, булмаганын шәһәрдә эшләүче иптәш кызларыннан сорап, ниһаять, ул авыруларны кабул итә башлады.

Авыруга беренче мәртәбә үзе яаган тешне куеп җибәрү өчен әйтеп бетерә алмаслык дулкынландыргыч бәйрәм булды. Авыруның аңа карап елмаюы, чын күңелдән рәхмәт әйтүе кызны канатландырып җибәрде.

Тиздән кызның даны Тарханга гына түгел, тирә-як авылларга да таралды. Аның кабинетына керү өчен чират көннән-көн зурайды. Ә теш куйдырганнар аны урамда очратсалар, рәхмәт әйтеп узалар.

Бөтен энергиясен биреп эшләгән бу кызны коллектив тиз күреп алды. Зур ышаныч һәм өмет баглап үзен Кызыл Хач җәмгыятенең председатель урынбасары итеп сайладылар, комсомол комитетының бюро члены иттеләр. Бу эшләрдә дә кыз үзен сынатмады.

Әнә шундый өлгер кыз инде ул безнең Галина.

**Укытучы шатлыгы**

Эмма Григорьевна, өеннән чыгып, чатны борылырга да өлгермәде, аны бер төркем укучылар куып җиттеләр. Аларның кайберләре болай да сх белән генә исәнләште, ә кайсылары йөгереп килү уңаенда укытучыны кочып ук алды. Шунда ук аның сумкасын, пөхтә итеп төрелгән арифметика дәфтәрләрен бүлешеп күтәрделәр дә, урамны яңгыратып сөйләшә-сөйләшә, мәктәпкә таба атладылар. Нәни дусларын тыңлау, алар белән сөйләшү укытучының күңелендә аерым бер дәрт уята иде.

Әмма күңеллелек озакка бармады. Класс бүлмәсенә аяк басу белән аның күз алдында коточкыч тәртипсезлек пәйдә булды. «Класс почмагы» ертып ташланган, идән кәгазь кисәкләре һәм пыяла ватыклары белән тулган.

Даиров Шәүкәт эше бу, – диештеләр иптәшләре.

Укытучының түгәрәк алсу йөзе караңгыланып китте, рухланып балкыган зәңгәр күзләрендә очкын сүнгәндәй булды.

Тагын шул Даиров! Әле үткән атнада гына иптәшен кыйнап елаткан иде. Өченче класста укыганда да рәте-кыны булмады. Классында утырып калдырырга да исәпләгән иде. Шулай да кызганды, аның дүртенче класста өлгерә алуына өметләнде. Даиров турында ялгышты микәнни ул. Әллә… Юк, юк, алай булуы мөмкин түгел.

Үзен генә алып калып та, ата-анасы белән дә әз сөйләшмәде. Тик нәтиҗәсе сизелерлек булмады. Ничек итеп бала йөрәгенә үтеп керергә соң, ничек аның йөрәгенә ачкыч табарга?

Укытучы башын күтәрде һәм:

Шәүкәт үзе кайда соң? – дип сорап куйды.

Әллә кайчан чыгып сызды инде ул, шәт, өенә үк кайтып киткәндер.

Әтисе-әнисе янына кабат барыргамы? Дөресрәге, алар сүзенә дә бик исе китми шул аның. Хәтта күршеләре дә Шәүкәтнең тәртипсезлегеннән зарланалар.

Укытучы бу юлы Шәүкәтнең әти-әнисе янына бармады. Шәүкәт дәрескә икенче көнне генә килде. Бернәрсә дә булмагандай, үзен иркен хис итте ул. Дәресләр беткәч, укытучы:

Шәүкәт, беразга кал әле, – дип аны туктатты.

Шәүкәт теләр-теләмәс кенә туктады.

Менә үткән атнада иптәшләрең белән класс почмагыясап элгән идек, аны кайсыдыр ертып ташлаган, – дип сөйләнә-сөйләнә укытучы өстәл өстенә зур ак җәймә җәеп салды. – хәзер яңадан ясарга туры килә инде. Син, Шәүкәт, миңа бераз булышырсың бит?

Шәүкәт үзенең гаебен тоеп кызарды. Үзен кая куярга белмичә уңайсызланды ул. Бер укытучыга, бер өстәлдәге кәгазьгә карап торганнан соң:

Миңа нишләргә? – диде һәм, сумкасын парта өстенә куеп, өстәл янына килеп басты.

Син хәзер менә болай сыза тор, аннары язарбыз.

Аның иптәшләре, Шәүкәтнең нинди уеннар белән мавыгуы турында сөйләшә-сөйләшә яздылар. Малай ачылып китте һәм рәхәтләнеп сөйләшә башлады.

Менә ничек шәп булды, – дип куйды укытучы, класс почмагын стенага элеп. – тагын берәрсе ертып китмәсә ярар иде инде.

Икенче көнне дә алар, бер эш табып, дәрестән соң калдылар. Ә аннары дәресләрдән соң өй эшләрен хәзерләргә күнегеп киттеләр. Алар янына Камил Мальков та, Нәзирә Вахитова да кала башлады. Ә берникадәр вакыттан соң укытучыны Таһирә Хәкимова, Гөлсинә Гомәрова, Минзәет Володкин кебек уку отличниклар алмаштырдылар.

Шәүкәт әкрен генә алга атлады. Укуыннан да, арифметикадан да өчле билгеләре күренә башлады.

Шулай рәткә баса дигәндә генә аның яңа гаебе ачылды. Ул тәмәке тарта икән. Иптәшләре бу турыда стена газетасына язып куйдылар. Ә соңыннан үзен класс җыелышында тикшерделәр.

Эмма Григорьевна Тюленева барлык эшне дә укучыларның үзенә тапшырды.

Сезнең иптәшегез, үзегез теләсәгез нишләгез – диде ул, иң арттагы партага утырып.

Укучылар, бер-беренә карашып, башта бер сүз дә дшми тордылар.

Аннары Хәкимова урыныннан сикереп торды да:

Һаман Шәүкәт тәртип боза. Аның аркасында безне класс артка сөйрәлә, – дип әйтеп куйды.

Әйтерсең барысы да шуны гына көткәннәр. Тотындылар Шәүкәте кыздырырга, түзеп кенә тор. Шәүкәт башта акланды, иптәшләренең әйткәннәрен юкка чыгарырга тырышты. Әмма соңга таба бөтенләй дәшмәс булды. Бу җыелыш Шәүкәткә тәэсир ясады. Аңарда шактый төзәлү, тырышлык сизелә башлады. Сирәк-сирәк булса да «4» дилгеләре дә алгалады.

Бу арада укытучының мәшәкате тагын да күбәеп китте. Язгы чәчү чорында агитация эшенә дә күбрәк вакыт бирергә туры килә, өстәвенә, авыл клубында чыгыш ясар өчен, концертка да хәзерләнәләр. Бер үк вакытта үз хыяллары, омтылышлары бар бит. Ул институтка читтән торып укырга керергә хәзерләнә. Интситутны бетергәч тә аның исәбе башлангыч классларны укыту. Нәни балалар блән эшләүне бигрәк тә ярата шул ул.

Менә хәзер дә егерме биш бала ягымлы итеп аңа карап тора. Ә шуларның яртысына якны уку алдынгылары. Кайчан гына әле алар партадан әз генә калку, хәреф, хәтта бер авыз русча сүз дә белми торган балалар иде. Хәзер шартлатып русча сөйләшәләр, фән баскычлары буйлап югарыга үрмәлиләр.

Бер-ике көннән ул алар белән саубуллашачак. Аналарыннан аерылган кош балаларыдай, алар бишенче класска күчеп китәчәкләр.

Ул аларны бик тә яратты шул, үз балаларыдай якын күрде. Аңа 25 пар ягымлы күз төблгәню һәркайсының үзенә генә хас характеры, омтылышы бар. Ә Эмма Григорьевна һәммәсенең дә йөрәгенә үтеп керердәй ачкыч таба алды.

Әнә Мальков, Вахитова, Даиров Шәүкәт мөлаем гына карап утыралар. Укытучыга шактый гына мәшәкать тудырдылар алар. Юкка гына укытучыны икенче ана дип әйтмиләр шул. Нинди ана үзенең баласының начар булуын тели. Укытучы да аналар кебек үк һаман яхшылык, һәркем тарафыннан макталып телгә алырдай чын кеше булуларын тели.

Тиздән алар җәйге походка, Ульяновскийга бөек юлбашчының туган-үскән җирләре күреп кайтырга барачаклар. Һәр укучы походка хәзерләнә, һәркайсының йөзендә үзенә бер дулкынлану, омтылыш балкый.

**Иҗат шатлыгы**

Петр Сергеевич Никушин өенә дулкынланып кайтып керде.

Кызлары идән уртаснда курча уйнап утыралар иде. Өчесе дә аңа таба борылдылар.

Кайттыңмы, әткәй…

Кайттым, кызым, кайттым, – дип Петр Сергеевич балаларны киң күкрәгенә кысты һәм үбеп алды.

Алар берсен-берсе бүлдереп, аталарына бүгенге яңалыкларны сөйләделәр дә яңадан курчакларына ябыштылар.

Ата балаларының мавыгып уйнауларына елмаеп карап торды да, алар янына чүгеште.

Шул чак Лида кайтып керде. Иренең шатлыклы йөзеннән ул барысын да аңлады.

Чын күңелемнән тәбрик итәм, – дип ирен кочаклап алды. – Бир әле, күрсәт, нинди була икән ул партия билеты!

Петр Сергеевич бер мәлгә уйга калды. Аның күз алдыннан октябрят, пионер, комсомолец булган көннәре үтеп киткәндәй булды. Бүгенгедәй үәтердә ул көннәр. Менә хәзер ул партия члены. Партия члены! Нинди горур яңгырый!

Мәктәптә дә яхшы укыды. ләкин җиденче классны бетергәч, укуын дәвам иттерергә генә туры килмәде. Әтиләр сугышта иде. Ә ана 5 бала белән калды. Өстәвенә әле авыру әбиләре дә бар иде. Ә ул чакта тормыш алып баруҗиңел булмады. 14 яшьлек Петя колхозда эшли башлады. Аннары аны тракторчылар курсына укырга җибәрделәр. Тракторчы булып эшләгәндә дә үзен сынатмады, норманы арттырып үти иде. Шул эштән армияга китте. Анда электромонтерлый һөнәрен үзләштерде. Армиядән кайткач, Олы Тархан РТСында электрик булып эшләде. Хәзер инде ул Олы Тархан лесничествосында механик.

Дөрес, хезмәт юлында аңа төрлесен күрергә туры килде. Әмма чигенмәде һәм кыенлыкларны җиңеп чыгарга өйрәнде.

Бүген алар өендә зур җантана. Болай да җитез Лида тагын да җиңеләеп киткәндәй булды. Өч эчендә кояштай очып йөрде. Кай арада самоварын кайнатып, ашын пешереп өлгерткән.

Чәй эчеп утырганда Лидасы:

Эштән кайтканда Геннадий Михайловичны очраткан идем. Анда сезнең бер машина җимерелгән бугай, – диде.

Шулаймыни?.. Нигә аны баярак әйтмәдең, – дип урыныннан сикереп торды Петр Сергеевич.

Бүген шундый шатлыклы көн. Бу хәбәр белән сине борчыйсым килмәгән иде, дип куйды Лида, ник әйтүенә үкенеп.

Мин тиз генә барып кайтыйм инде, әнкәсе, бик озак тормам, – дип Петр Сергеевич чыгып китте.

Лесничество мөдире Геннадий Михайлович Тюленев аны ачык чырай белән каршы алды.

Ишеттем, ишеттем, молодец, – дип чын күңеленнән тәбрикләде.

Бераз сөйләшкәннән соң Никушин:

Машиналарның барысы да эштәме? – дип сора куйды.

Кая киле чыга, иртәгә планны тутырабыз дигәндә генә…

Нәрсә булды? – дип түземсезләнеп сорап куйды механик.

Әнә Куртаев Мөкатдәс машинасының тормозы җимерелгән.

Петр Сергеевич машинасы янына ашыкты. Әмма Геннадий Михайлович уйлаганча, эш җиңел генә җайга салынмады. Тормоз дискын яңага алыштырырга кирәк булып чыкты. Ә запас

часть, үч иткәндәй, лесничество мастерскоенда да, хәтта Тархан РТСында да табылмады. Шуннан соң алар Урюм РТСына мөрәҗәгать итеп карадылар. Анда да булмагач, Тәтеш «Сельхозтехника» сына шалтыраттылар.

Нишлибез соң инде хәзер, – дип ачынып әйтеп куйды Геннадий михайлович. – Мин бу айда планны йөз илле процентка үтәрбез дип тора идем.

Петр Сергеевичның да чырае караңгыланды. Өенә кайткач та бу тормоз аның исеннән чыкмады. Төнлә дә тыныч йоклый алмады.

Нигә шул кадәр борчылырга, – дип тынычландырмакчы булды аны Лидасы.

Булмаганга син гаепле түгел ич.

Машина эшсез тора, – дип авыр сулап куйды Петр Чергеевич. – План өзелә.

Уйланды, уйланды да сикереп торды, үзенең техник китапларын актара башлады. Тик аннан күңелен басардай бернәрсә дә таба алмады. Тагын ятты. Ничек кенә булса да йокларга тырышты. Уйлар тынгылык бирмәделәр. Тагын сикереп торды, клына каранаш алып, нидер сза башлады. Ертып ыгрытты, кабат сызды, тагын исәпләде…

Икенче көнне алар шофер белән кызу эшкә керештеләр. Кул тормозының ватык ватык чуен барабанын үзләре ясаган тимер барабан белән алыштырылар. Тагын башка җайланмалар ясаганнан соң, машинага икәү утырып сынап карадылар.

Бик шәп булган бу, Петр Сергеевич, – дип куйды Мөкатдәс, шатлыклы елмаеп. Машина янына директор да килеп җитте.

Молодцы, егетләр, булдыргансыз, – дип мактап куйды. Аннары Никушинга карап. – Кара син нинди егет икәнсең, Петр Сергеевич, – дип дәвам итте. – Бу яңалыкны башка машиналарда да кулланырга кирә булыр.

Һәм чынлап та кулланырга туры килде. Шундый ук тормозны Петр Сергеевич Килдеш лесничествосында эшләүче шофер Василий Подгорныйга ясап бирде.

Беркөнне Никушин лесничествоның тимерчек алачыгына ашыгып килеп керде.

Эшләр харап, Нотфулла абый, ди эндәште ул тимерче Гыймадиевка. – Автокранның тормоз «собачка» сы ватылган. Аны безнең район мастерскойларында түгел, Казанның үзеннән дә табуы бик читен.

Нотфулла абзый авыр чүкечен җайлап кына куйды да, маңгаендагы тирен кулы белән сөртеп алды..

Тыңлыйм, энем, – дип куйды ул, кайгы уртаклашкан сыман һәм папирос көйрәтеп җибәрде.

Мин күп уйладым инде, менә сызымым да бар, – дип механик куен кесәсеннән кәгазь тартып чыгарды.

Ул үзенең планнарын тимерчегә аңлатканнан соң:

Ничек уйлыйсың, Нотфулла абый, шуны эшли алырбыз микән? – диде.

Ай-һай, энем, белмим шул.

Алар эшкә керештеләр. Билгеле, уйлаган планны ахырына җиткергәнче шактый көч түгәргә килде. Ниһаять, үзләре ясаган механизмны сынап карадылар. Икесенең дә чырайлары яктырып китте.

Булды бит бу, энем.

Тәки башкардык бит, Нофулла абый. Кулың алтын дип тикмәгә генә әйтмиләр икән шул.

Нишләрмен инде хәзер дип бик борчылган идем, – дип кранчы Талип Галиуллин да сүзгә кушылды. – Рәхмәт сезгә, бик зур рәхмәт.

Автокранны урманга озатып мехник ял итәргә дә өлгерә алмады. Мәүлет Куркин чабып килеп битте.

Тагын шпилька сынды, петр Сергеевич, – диде Мәүлет, мазутланган бияләйләрен җиргә атып. – тәмам аптырады бит инде.

Механикның дачырае бозылды. Куркин тракторына «Бугиль» шпилькасының соңгысын куеп җибәргән иде инде ул. Хәзер ансын каян алырга инде.

Бу айда гына да тке-өч «Бугиль» шпилькасын ваттырган өчен ул Куркинны ачуланып та ташларга уйлаган иде, шулай да ул үзен тыеп кала алды.

Мәүлет тә механикның фикерен сизенепмедер:

Сынуы бер хәер иде әле. Аны ремонтлап булмый, һаман яңа белән алмаштытырырга туры килә. Нигә шул «Бугиль» шпилькасын заводтан ук ремонтларга мөмкин булырлык итеп ясап чыгармыйлардыр.

Петр Сергеевичның тагын яңа кайгысы артты. Өстәл артында төн озын уйланып утырды. Күпме баш ватты, күпме кәгазь буяды. Эшкә килгәч тә уе һаман шул «Бугиль» шпилькасы турында иде. Ул инде аны кулында туксан тугыз мәртәбә әйләндереп карагандыр.

Кинәт ниндидер өмет чаткысын сизгәндәй, йөзе яктырып киитте.

Кара әле, шайтан алгыры, болай эшләргә була иде бит аны, – дип җилкенеп куйды ул. Шулай да шпильканң ныклы булуына шикләнә иде. Тиз генә мотоциклына утырды да РТСка чапты. Андагы белгечләр белән киңәште һәм эшләп карадылар.

Чынлап та бу фикер начар түгел, – дип хуплады ны баш инженер.

Җайланма үзе гади генә, әмма хәзер «Бигуль» шпилькасын тулысынча металлоломга ыргытырга туры килмәячәк, үзәк буенча тишелгән эз аның детален җайлы гына алыштырып куярга мөмкинлек бирәчәк.

Бу яңалык Урюм РТСы механигы Фроловка да барып җитте. Ул да Никушин тәкъдиме буенча эшләп карады.

Кырык ел механик булдым, шуңа башым җитмәгән, – дип ул Никушинны мактап та алды. – Башлы егет.

Петр Сергеевичның тик торган вакытын күрмәссең. Әле генә мастерскойда була, ул да түгел аны яшь механизаторлар янында күрәсең. Аның кул астында күп кенә яшь белгечләр «канат чыгардылар». Әнә Степан Одаряев белән Николай Ниткасовка гына карап торыгыз. Трактор детальләрен ничек оста итеп электр белән кыздырып ябыштыралар алар. Болар Петр Сергеевичның җимешләре бит. Әле кайчан гына электр белән ябыштыру механизмына орынырга да куркып торалар иде. Ә Рифкать Җәгъфәров, Рәис Рәхмәтуллин, Сәгыйть Фәткуллиннарны трактор «йөрәген» аңлап бетерергә, аның тибешенә карап «сәламәтлеген» аерырга кем өйрәтте дип беләсез. Болары да Петр Сергеевичның җимешләре.

Күптән түгел генә әллә кайчан металлоломга тапшырылган детальләрне җыеп менә дигән механизм ясап куйды. Аның бу машинасы бер үк вакытта чар да була, автомашина балоннарына һава тутыра ала.

Безнең Петр Сергеевич чын рационализатор, – дип мактый аны Геннадий Михайлович. – Ул ясаган паркет станогы гына да безнең өчен зур байлык. Өстәвенә чәчү һәм агач утырту җайланмалары һәм башка унлаган тәкъдимнәрне безнең хуҗалыкны алга җибәрүгә зур этәргеч булды.

Петр Сергеевич Никушинның партиягә кабул ителүенә икенче генә ел әле. Шулай да ул үзендә нык үзгәреш, үсү сизә. Аның күбрәк беләсе, күбрә укыйсы килә. Үзенә әллә ничә исемдәге газета һәм журналлар өстенә техник журналлар да алдыра. Чын-чынлап тормыш-баскычлары буйлап биеклеккә үрмәли ул. Рухланып дәртле күңел белән эшли.

### Тормышның мәгънәсе

Иртән көн аяз, җилсез иде. Кичкә җаба җил чыкты, буран күтәрелде. Телефон баганалары, үксеп елаган балалардай, шайлый башладылар. Авылны әкрен генә караңгылык пәрдәсе томалады, өйләрдә ут кабынды.

Барысы да җылы итеп ягылган өенә яшеренде. Урамнар беразга тынып калгандай булды. Бу вакытта Никадр Артемьевич Федотов та өйдә иде. Нәрсәгәдер борчылды. Тышта буран басылмаганмы дип әле тәрәзәгә килеп карады, әле ишекле-түрле йөрде. Бүген комсомоллар белән политзанятие көне. Ул сәгатенә карады. Нишләргә? Үз авылына гына булса да, ни әйтер идең. Шушы буранда өч километр юл үтәсе бар. Әгәр бүгенгә бармасаң? Ул кабат ишекле-түрле йөрде. Уйланды. Аннары тиз генә киенде дә юлга чыкты.

Күңел генә курка икән, бер юлга чыккач җиле дә, бураны да җиңелә. Баштагы уйлары, икеләнүләре өчен үз-үзен тиргәп тә алды: «Коммунист имеш, җебеп калдым, әйтерсең мондый бураннарда йөргән юк иде. Оят, оят…» Төрле уйларга бирелеп атлый тргач Тарханбаш белән Олы Тархан арасы сизелми дә калды. Әллә инде бераз буран да басыла төште шунда.

Комсомол яшьләр белән олитзанятие Олы Тархан клбының аерым бүлмәсендә үтә. Никандр Артемьевич клеп җиткәндә дәрес башланырга вакыт җитмәгән иде әле.

Кинәт аның карашы афишага төште һәм йөрәге жу итеп куйды. Бүген клубта яхшы кино булачак. Ззанятиега йөрүче комсомол членнары, мөгаен, кинога керерләр. Шушы буранда арып-талып килүе бушка китмәсме? Бу дәрескә яхшылап хәзерләнде, парткабинеттан аңа диафильмнар да алып килгән иде.

Исәнмесез, Никадр Артемьевич.

Ул борчулы уйларыннан аерылып, тавыш килгән якка борылды һәм сүрән генә:

Исәнмесез, Рәмзия, кинога килдеңме – диде.

Юк, – диде Рәмзия, ягымлы елмаеп, – дәрескә килдем.

Башкалар да җыелдылар. Менә гаҗәп, килгән бер комсомолец тамаша залына түгел, политзанятиене үтәчәк бүлмәгә җыелды.

Кино да, политзанятие дә бер үк вакытта башланды. Пропагандист яшьләргә карап эчке бер уү рухлану белән елмайды:

Ярый, иптәшләр, дәресебезне башлыйк.

Ул иптәп кенә утырды, үткән темага карата сорай бирде:

Фирдәвес, – алсу йөзле коңгырт-кара чәчле кызга текәлеп карады, – бу сорауга син ничек җавап бирерсең?

Кыз торып басты һәм башын горур гына артка чөеп сөйли башлады…

Прорагандистның күз алдыннан беренче занятие үтте. Бу көнне занятие үтте. Бу көнне занятиегә 26 кешедән бары 3әү генә клгән иде. Бик тә борчылган иде ул бу көнне. Пропагандист булып эшләвенә беренче ел гына түгел инде аның. Әмма шушындый хәлне беренче очратуы иде. Комсомол оешмасы пропагандист итеп билгеләгәч тә партком секретаре Я.Г. Әхсәнов:

Елның-елында бу комсомол оешмасында политзанятиеләр нормаль узмый. Билгеләнгән пропагандисттан һич тә уңганыбыз юк. Мәктәп партия оешмасы секретаре Одаряева Анна Яовлевна белән дә киңәштек һәм менә сезгә тукталып калдык. Билгеле җиңел булмас, өстәвенә чит авылда яшәегез дә кыенлык тудыра. Шулай да Сезгә ышанабыз, – дигән иде…

Никандр Артемьевич комсомол-яшьләр белән эшләргә бик ярата. Дөресрәе, аның күпчелек гомере яшьләр белән эшләп үтте. Беренче мәртәбә мәктәптә укытырга башлаган елы гына иде әле. Аны башлангыч комсомол оешмасының секретаре итеп сайладылар. Ул яшьләр белән эшне шул кадәр оста һәм кызыклы итеп оештырды, аны районда да тиз сизепалдылар һәм (ул вакытта район үзәге Олы Тарханда иде әле) бюро членлыгына тәкъдим иттеләр. Аннары Олы Тархан ВЛКСМ райомының секретаре итеп сайладылар. Бер үк вакытта ул Казан педагогия институтында читтән торып укыды.

Олы Тархан районы Тәтеш районы белән берләшкәч, Никадр Артемьевич укытучылыр эшенә күчте. Укытучы булса да, комсомол-яшьләрне онытмады, алар белән политзанятиеләр үткәрде.

Дөресен генә әйткәндә, нинди дә булса җәмәгать эше башкармаса, тормышының кайсыдыр бер чите ким, нәрсәдер җитешми кебек тоела иде. Тормышның барлык тәмен, яшәүнең ләззәтен халык белән эшләүдә тоя да ул.

Быел җәй, ул отпускада вакытта, аңа «Алга» колхозында пионер лагеры оештыруны тапшырдылар. Ә пионер лагеры бу колхозда беренче мәртәбә оештырылды! Тау кадәр кыенлык. Ә ул чигенмәде. Урман эчендә урнашкан пионер лагерында укучылар рәхәтләнеп ял иттеләр, көч тупладылар… Әйе, беренче занятиегә өч кенә кеше килде. «Барыгыз, иптәшләр, бүгенгә кайтып торыгыз, дәресне барыгыз да җыелгач үткәрербез», – дияргә хакы бар иде аның.

Юк, Никадр Артемьевич алай эшләмәде, өч кеше генә була да занятиене үткәрде һәм мөмкин кадәр кызыклырак үткәрергә тырышты. Ә икенче занятие комсомолецлар күп җыелган иде, ә аннары сәбәпсез дәрескә килмәүчеләр булмады.

Менә бүген дә шатланып бетә алмый. Залда яхшы кино бара. Ә комсомол членнары кинога түгел, занятиегә кереп утырдылар.

Димәк, шатланырлык урын бар, биредә аның хезмәт җимеше сизелә.

Үткән дәресләрне кабатлаганнан соң, пропагандист яңа дәресне башлады.

Ул темага карата төрле кызыклы эпизодлар сөйләде, диафильм күрсәтте. Дәресбеткә тә комсомоллар тз генә таралып китмәделәр. Тагын әллә никадәр сораулар бирделәр. Ә пропагандист иренмәде, сөйләде дә сөйләде.

**Тормыш баскычлары буйлап**

Төн. Ай яктысында кар энҗе бөртекләре кебек ялтырый. Аяз күк йөзенә сибелгән йолдызлар бераз салкынча төнгә сихри матурлык өстиләр. Һава чиста, саф. Сулыш алуы рәхәт. Шундый соклангыч айлы төндә өйгә бер дә кермичә йөрисе, һаман йөрисе, табигатьнең гүзәллегенә чумып хыялланасы, каядыр омтыласы килә.

Менә хәзер генә авыл клубында концерт куеп чыккан Валентина Дмитриевна Савельчеваның күңелендә шундый тойгы иде.

Ул әкрен генә атлый, гүя шушы сокландыргыч төннең бөтен гүзәллеген үзенә җыеп каласы килә иде. Шулчак кар шыгырдаган тавыш аның колагына килеп бәрелде. Валентина Дмитриевна артына борылып карады.

Кемдер аңа таба ашыга иде. Килеп җиткәч тә бер мәлгә тукталып калды һәм, сулышын көчкә алып, Валентина Дмитриевнаны кочып алды.

Көтелемәгән бу хәлдән Валентина Дмитриевна югалып калгандай булды һәм кочагындагы кешене танып:

Бу сиңа ләбаса, бәгырькәм Вера – дип Никонорова Вераның аркасыннан чәбәкләде. – Каян җил ташлады?

Менә бер-ике көнгә дип авылыма кайткан идем. Сезне дә күрәсем килде. Бик тә сагындым үзегезне. Өегезгә кергән идем, клубка китте диделәр. Клубка киттем. Карагыз әле, сез чын артистка икәнсез. Сезнең җырлаганны тыңлаганда мәктәптә укыган чакларым исемә төште. Сез ул чакта бик яшь идегез әле. Хәтерегездәме, без сезнең белән бергә Тархан, Киртәле, Кадыш клубларында концерт куеп йөри идек.

Онытыламы соң ул чаклар!

Ә Килдешкә концерт куярга баргана да шундый айлы кич иде. Сез үзегезнең мәктәптә укыган чакларыгызны искә төшереп сөйләгән идегез.

Алар шула үткән гомерне мәктәп чорларын искә алы бераз атлаганнан соң Валентина Дмитриевна:

Мин синең өчен бик шатмын, Вера, – дип әйтеп куйды. – Син хәзер зур кеше – доцент дәрәҗәсенә ирешкәнсең. Эшең шунда, Казан авыл хуҗалыгы институтындадыр бит?

Әйе, шунда, – диде Вера. – Минем дәрәҗә – синең тәрбия нәтиҗәсе, Валентина Дмитриевна. Сез һаман безгә: «Беркайчан да тукталыш ясамагыз, тормыш баскычлары буйлап өскә, һаман өскә үрмәләгез!» – дия идегез.

Күптән түгел Меньшов та кайткан иде. Аэродромда очраштык. Ул шундый үскән, матурайган, олыгайган. Чоданнарын читкә куйды да, каршыма йөгереп килде. Ягымлы гына исәнләште дә: «Мине танийсызмы соң, Валентина Дмитриевна?» – ди. Ябыграк гәүдәле, шаян, шат күңелле малай кылт итеп искә төште. «Меньшов» – мин әйтәм. «Әйе, мин шул, мин», – ди бу үзен укытучысы таныганга бик тә шатланып. Аннары ул янәшәсендәге хатынына борылып: «Бу – безнең рус теле, әдәбият укытучыбыз Валентина Дмитриевна», – дип мине тормыш иптәше белән таныштырды. Ул хәзер Брежнев шәһәрендә инженер булып эшли икән.

Вера белән бу очрашудан соң Валентина Дмитриевна яшьлегенә әйләнеп кайткандай булды.

Быел аңа 50 яшь тулды. Кай арада ярты гасыр гомер үтеп киткән соң әле. Әле кайчан гына Олы Тархан урта мәктәбенә укытучы булып килгән иде. Аңа да хәзер чирек гасыр үтеп киткән.

Украинада яшәүче әнисенә (ул үзе дә шунда туып-үсә, шунда белем ала) «Мине язмыш татар авылына китерде. Бу авыл үзе бик зур, мәктәбе дә зур. Анда дүрт милләт: татар, рус, мордва, чуваш балалары укый» дип язгач, әнисеннән бик борчылып язган хат алган иде. Болай да яраткан кызының читкә киткәнен авыр кичергән ана, шул татар аылында югалыр инде кызым, санга да сукмаслар үзен, абруе да булмас, дип уйлагандыр.

Үзенең тырышлыгы, ягымлылыгы кешелеклелеге белән үзен тиз танытты Валентина Дмитриевна. Ышанычлы юл ярды ул. Укучыларына үзе өйрәткәндәй, тормыш баскычлары буйлап һаман өскә, югарыга үрмәләде.

Гади укытучы, класс җитәкче булып күп тә эшләмәде ул, аны завуч итеп билгеләделәр. – Ул уңайсызланды. Коллектив зур, көчле, тәҗрибә укытучылар күп. Ә ул 5–6 ел элек кенә тормыш сукмагына баскан яшь укытучы. Өстәвенә гаилә, яшь балалар.

Сиңа ышанып тапшырылган эшкә каршы төшә алмыйм, – дип киңәш итте тормыш иптәше Петр Степанович.

Ә йорт, балалар, мал-туар?

Кайгырма, барысын да бергә эшләрбез, – диде Петр Степанович. – Балалар үсәр. Бераз кул астына кергәч, алар булышыр.

Һәм шулай булып чыкты да. Валентина Дмитриевна йорт эшләреннән тулысынча азат итмәделәр итүен. Әмма аңа барысы да җиң сызганып булышты. Ә йорт эшләреннән бушагач, ул дәресләренә утырды. Алар өендә ут бик озак янды. Балалар үсә барган саен аңа бераз җиңеләя төште. Һәркайсының билгеләнгән эше бар иде бу йортта. Берсенә дә син моны эшлә, дип кушып торасы юк иде.

Гаилә дә ишәя барды. Һәр туган бала аларга шатлык, бәхет, киләчәккә өмет алып килде.

Биш бала. Иң олысыкыз, калганнары ир бала – барысы да уңган булып чыктылар. Олы кызлары Лена педагогия институтын тәмамлап, әние юлыннан атлады. Алеша белән Володя да мәктәпне алтын медальгә бетерделәр. Казан Дәүләт университетына укырга кереп, әниләре сукмагын сайладылар.

Хәзер яннарында 9 класста укучы Гриша белән 5 класста укучы Петя гына калды.

Их, әнкәй, әнкәй, – дип куйды Валентина Дмитриевна әнисенең беренче хатларын искә төшереп.

Юкка гына борчылган икән шул мескен ана. Валентина Дмитриевна татар авылында бер дә югалмады. Киресенчә, авылның һәр кешесе аны хөрмәт итте, олылады. Коллективның ул иң яраткан кешесенә әйләнде. Район Советына да авыл Советына да күп мәртәбә депутат итеп сайладылар үзен. Менә хәзер дә әле ул авыл Советы депутаты.

Аңа эш мәктәптә дә, округта да күп, бик тә күп. Өстәвенә әле ул куст методик берләшмәсе җитәкесе. Әмма ул беркайчан да эш күплектән зарланмый. Һәркайсын җиренә җиткереп үтеп бара. Барлык эшләр дә яңадан-яңа омтылыш яңа дәрт кенә өсти шикелле. Гомернең бер генә минутының да эшсез үтүен күз алдына да китерә алмый ул.

Моннан сигез ел элек кенә аны «Почет билгесе» ордены белән бүләкләгәннәр иде. Аның йөрәгенә тагын бер шатлык өстәлде. Үткән ел ана «РСФСРның атказанган укытучысы» дигән исем бирделәр…

Вера саубуллашып киткәч тә Валентина Дмитриевна үзенең үткән көннәрен искә алып, озак йоклый алмыйча тты. Үзендә укыган һәр укучысы күз алдына килеп басты аның «Тукта әле» дип сикереп торды да ул йоклаганнар уянмасын дип йомшак кына атлап арт бүлмәгә чыгып ут кабызды. Китаплар киштәсеннән бер төргәк алып өстәлгә куйды. Бу укучыларыннан килгән тәбрикләү карточкалары иде. Шуларны карап чыкты ул. Әнә бу хатлар күпме! Аларның берсен дә югалтмый ул, саклый. Һәр хат. Һәр сәламләү, һәр тәбрикләү укытучы өчен ң зур бүләк ул.!

Шуларны кулга алгач та укучысы аның күз алдына килеп баса. Ә укытучы күңеленнән алар белән сөйләшә, киңәшә.

Ул кайчан ятып, ничек йоклап китүен сизмәде. Шулай да ул барысыннан да иртә уянды.

Мәктәптә аны укучылар ягымлы йөз белән каршы алдылар. Ул алар белән исәнләшә-исәнләшә үз бүлмәсенә атлады.

Күп тә үтмәде телефон шалтырады.

Валентина Дмитриевна, хәерле иртә. Сезне РОНО мөдире Рәхим Гарипович борчый. Тиздән район укытучыларының район укытучыларының киңәшмәсе була. Сезнең мәктәптә яшь укытучылар күп. Шулр белән эшләү тәҗрибәсен уртаклашырсыз дип ышанасы килә.

Ярар, Рәхим Гарипович, тырышырмын.

Укытучының эш көне дәвам итте.

Хуш киләсез, кунаклар!

*Олы Тархан урта мәктәбендә уку елы барышында уздырылган «Дуслык» фестивалендә катнашучылар күңелендә озак сакланыр*

Олы Тархан урта мәктәбендә бу көнне аеруча зур җанлылык хөкем сөрде. Чөнки бирегә «Дуслык» фестиваленә Кадыш, Бессоново Киртәле, Бакыры сигезьеллык һәм Бидәңге, Кошки-Ново-Тимбаево урта мәктәпләреннән кунаклар киләчәк.

Фестивальне оештыручылар Расих Ипталович Шагаев һәм Роза Әхмәтовна Гыйсмәтова аеруча дулкынланалар. «Барысы да килерләрме, ничек үтәр?» дигән сорау аларның күңелен борчый.

Кемдер шунда:

Киләләр! – дип кычкырып куйды.

Бер мәлгә мәктәп эче тыны калгандай булды.

Кунакларны каршы алу, урнаштыру һәм башка мәшәкатьләрне расих Әхмәтовна баштан ук уйлап, планлаштырып куйганнар иде. Бу ике укытучы фестиваль планын да кат-кат карап чыктылар. Һәркайсының бу көннәрдә мәшәкатьләре күп булды. Мәктәптә тәрбия эшләрен оештыручы Роза Әхмәтовна һәр мәктәпкә кат-кат шалтыратып, аларның фестивальгә ничек хәзерләнүләре белән кызыксынып торды.

«Киләләр!» дигән тавыш Расих Инталович белән роза Әхмәтовнага канат куйгандай итте. Алар, бер-беренә канәгатьләнү карашы ташлап, чиксез шатлануларын белдерделәр дә, ишеккә ашыктылар.

Мәктәп бусагасын беренче булып иң ерак кунаклар – Кошки-Ново-Тимбаево мәктәбе укучылары атлап керде. Аларны VIII «Б» класс укучылары ипи-тоз белән каршы алдылар һәм

үз класс бүлмәләренә – физика кабинетына алып керделәр. Үзара танышканнан соң, мәктәп эшләре, укулары, ял итүләре турында сөйләштеләр.

Озак та үтми башка мәктәпләрдән дә кунаклар килеп бетте.

Бераздан барысы да залга җыелдылар. Биредә үзара танышып, дуслашып өлгергән төрле милләт балалары – татарлар, руслар, чувашлар, мордвалар – туганнарча очраштылар.

Мәктәп залы аеруча матур бизәлгән иде. Бер якта һәрбер мәктәп үзенең күргәзмәсен оештырган. Нидәр генә юк анда: укучылар куллары белән эшләнгән милли чигешләр, агачка уеп эшләнгән рәсемнәр, милли ашамлыклар һәм башка бик күп төрле әйберләр.

Һәрбер мәктәп укучылары үзләренең милли костюмнарын киеп килгәннәр.

«Дуслык» фестивален үткәрү өчен жюри сайлаганын һәм башка оештыру эшләре үткәннән соң, сәхнәгә Расих Инталович чыгып басты.

Кадерле укучылар, укытучылар һәм кунаклар! Без яши торган планета – Җир – бары тик бер генә, – дип сүз башлады ул һәм үзенең барлык уй-фикерләрен үзе язган шигырь белән әйтеп бирде.

Трибунада – Кошки – Ново – Тимбаево урта мәктәбенең X класс укучысы Юля Семенова. Ул үзләренең крайны өйрәнү музееның эше турында бик кызыклы итеп сөйләде.

Һәр мәктәпнең вәкиле сүз алды. Алар үз мәктәпләрендәге эшләр, укулар һәм ирешелгән уңышлар турында һәркемне җәлеп итеп сөйләп бирделәр.

Шулай итеп, «Дуслык» фестивале башланып китте. Мәктәп залы гөрләп торды. Һәрбер мәктәп бу фестивальгә яхшы, үзенчәлекле һәм кызыклы итеп хәзерләнгән.

Фестивальнең концерт программасын йомгакларга Кадыш сигезьеллык мәктәбе укучыларына туры килде. Алар уен, җыр һәм бию номерларын башкарганнан соң мордва телендә «Һәрвакыт булсын кояш» дигән җырны башлап җибәргәннәр иде, аны залда утыручы Киртәле сигезьеллык мәктәбе укучылары да күтәреп алды. Алар бетерүгә, бу җыр татар, чуваш, рус телләрендә бер-җер артлы кабатланып торды. Шул кадәр дулкынландыргыч һәм шатлыклы иде бу минутлар.

Соңыннан ярышларга өч юнәлештә: балалар иҗаты, милли ашамлыклар һәм концерт номерлары конкурсына нәтиҗә ясалды. Җиңүчеләргә бүләкләр һәм Мактау грамоталары тапшырылды. Беренче урынны Олы Тархан урта мәктәбе укучылары, икенче – Кошки-Ново-Тимбаево урта мәктәбе укучылары, өченче урынны Бакырчы сигезьеллык мәктәбе укучылары яулады.

Кунаклар тиз генә китәргә ашыкмадылар мәктәп кабинетлары, Ленин һәм пионер бүлмәләре һәм музей белән таныштылар. Аларга барысы да ошады һәм музей журналына: «Сокл» ндыргыч бай һәм акыл белән төзелгән…» дигән язма да калдырдылар.

Укучылар дусларча, бер-берсен үз мәктәпләренә кунакка чакырып аерылыштылар.

«Дуслык» фестивале һәркем күңелендә озак сакланыр.

**Язмыш**

Көтмәгәндә, уйламаганда Сәйпиев Әнәс бәлага юлыкты. Бу хәл урманда була. Ул 25 яшеннән тол калган, сугышта ирен югалткан 82 яшендәге әбисенә утынга бара. Шундый изге юлда йөреп тә, ничектер абынып китеп, трактор астына эләгә ул. Күрәчәк аяк астында диләр, дөрес икән. Әнәс 12 яшеннән 62 гә кадәр колхозда эшләде. Печәнен дә чапты, урагын да урды, урманын да кисте, атын да җикте, шофер да булды, балта остасы да, ашлык складына мөдирлек тә итте. Соңгы 22 елын трактор отрядының кирәк-яраклар (запчастьлар) складына эшләп ялга китте.

Ата рәхәте дә күрми үсте ул. 6 баланы калдырып әтие үлеп киткәндә бик яшь де әле. (Әнәс 6 баланың төпчеге) әтисенең:

Улым, кешеләргә игелекле бул, аларны урынсызга рәнҗетмә, кеше малына кул сузма. Әгәр авылда берәүнең үлеп китүен ишетсәң, эшең ничек тыгыз булса да, аны соңгы юлга озатудан һич тә тартынма, – дигән сүзләре аның күңеленә тирән уелып кала.

Әнәс шушы көнгәчә атасының сүзләренә турылыклы булып яши. Кешеләргә ярдәмчел, киң күңелле, күркәм холыклы булганы өчен Олы Тарханда аны хөрмәт итәләр.

Җитмешне ваклап килгәндә шундый бәхетсезлеккә юлыгырмын дип кем уйлаган. Нишлисең бит, язмышы шулай булгандыр инде. Язмыштан узмыш юк, дип юкка әйтмиләрдер шул.

Шунда якында гына эшләүче урман хезмәтчәннәре, бу хәлне күреп ярдәмгә ашыгалар.

Шул арада Куртаев Фәннур да КамАЗы белән клеп җитә. Җафаров Илгизәр беән итәкләренә яткырып аны Олы Тархан хастазанәсенә кайтаралар.

Хастаханәнең баш табибы Равил Харисович Әнәснең изелгән, сынган җирләрен тикшереп, кирәкле медицина ярдәмен күрсәтәннән соң, аңа ашыгыч рәвештә операция кирәклеген ачыклый. Шул арада ашыгыч ярдәм машинасы белән Насыйров Дамир да киле җитә. Авыруны үзәк район хастаханәсенә җибәрәләр. Шәфкать туташы Малова Валя аны озата бара. Машина кузгалып китү белән, Равил Харисович:

Бездән бик авыр авыру юлга чыкты, операциягә хәзерләнеп куегыз, – дип үзәк хастаханәгә шалтырата. Бу хәбәр операция бригадасын аяка бастыра. Машина килеп җитү белән, Әнәсне операция бүлмәсенә кертеп салалар. Шунда ук ретнгенга төшерәләр һәм операциягә керешәләр.

Наркоз бирүче Шиһабетдинова Татьяна Борисовна, дулкынланып:

Әнәс, ишетәсеңме мине, күзеңне ач әле, – дип авыруны аңына китерергә тырыша. Аннары операция ясаучы табиб Назартаганов Нури Нуриевичның ишарәсе белән наркоз бирә башлый.

Операция башлана. Шәфкать туташы Моисеева Галина Александровна, зур осталык белән, кирәкле осталык белән, кирәкле инструментларны Нури Нуриевичның кулна биреп тора.

Ә Сучков Иван Иванович Нури Нуриевичның һәр хәрәкәтен күзәтә. Ул да нык дулкынлана, борчыла. Күпме авыруларны аякка бастырган табб Иван Ивановичның Әнәснекенә охшаган имгәнүне, мөгаен, күргәне дә булмагандыр.

Әле ярый Әнәскә кан бирүчеләрне озак эзләргә туры килми. Улы белән кызының кан группалары атасыныкы шикелле иде. Башта канны алардан алдылар. Аннары Яруллина Зөлфия Зиннуровна да зур теләк белән үзенең канын тәкъдим итте.

Операциядән соң да Әнәснең хәле җиңел түгел иде әле. Шул кадәр имгәнгән гәүдәнең хәле җиңел буламы соң?! Әле ярый, эчке органнарда артык зыян юк.

Табиблар авыру янында еш булалар. Шәфкать туташлары да авыру яныннан китми диярлек. Хастаханәнең баш табибы Җәгъфәров Вил Фоатович та авыруны күз уңыннан ычкындырмый.

Татьяна Борисовна:

Әнәс, хәлең ничек? – дип сорашып аңарда яшәү чаткылары уятып һаман кереп-ыгып йөри.

Киеренке авыр көннәр бер-бер артлы үтә тора. Әнәсне сагалап торган «Газраил» юкка чыга. Авыруга күкрәк читлеге тиңентен гипс салалар.

Иван Иванович күптән ялга ктәргә җыенган була. Әмма бу авыруны шул хәлендә ташлап китәсе килми аның.

Ниһаять, ул Әнәсне аякка бастыра. Дөрес, култык таяклары белән генә әле. Аны үлем тырнагыннан алып калдылар, ул – аякта. Табиб өчен моннан да шатлыклы минутлар бармы икән!

Ну, Әнәс, мин хәзер тыныч күңел белән ялга китәм. Хәзер инде барысы да үзеңнең тырышлыгыңнан, чыдамлыгыңнан тора, – дип Иван Иванович аңа соңгы киңәшләрен бирә. – Без әле хәзергә ялгыз калдырмыйбыз. Сине ышанычлы, зур тәҗрибәле табб Низамов Рафаэль Абдрахман улы караячак. Аның киңәшләре сиңа закон булыр… Бераз чыныкканнан соң өеңә кайтарып җибәрербез.

Көннәр, көннәр артыннан атналар, айлар бер-бер артлы үтте.

Мин авыруның хәлен белгәләп йөрдем.

Беркөнне аларга барганда ул ишекле-түрле йөри иде. Кәефе яхшы, чырае якты, күңеле күтәренке.

Нихәл, Әнәс, хәлләрең ничек? – дип сораштым мин.

Аллага шөкер. Менә култык таяклары белән булса да, йөри алам инде хәзер, – диде ул, шатлыклы йөз белән. – Мине үлемнән алып калучы барлык табибларга, шәфкать туташларына аеруча зур рәхмәтлемен. Минем хәлемне белеп торучы туганнарыма, якыннарыма, дусларыма да бик зур рәхмәт әйтәсем килә. Алар миңа яшәү дәрте биреп тордылар.

**Серле сәяхәт**

Шешәләр бер-бер артлы бушадылар. Шулай да ике дусның бер-берсеннән аерылышасы килмәде.

Тагын берне ватыйкмы әллә, – диде райпотребсоюзның скад мөдире Вахитов Мостафа – урныбыз яхшы, тыныч, закуска белән буа бу, җитмәсә тагын табарбыз.

Әмәллә, алайса, – диде Кадыш сельпосының склад мөдире Рәимов Хәммәт, – иртәгә ял, баш төзәтергә дә өлгерербез, – дип башын түбән игән килеш салып биргәнне бушата барды.

Аларның стаканнары бергә килеп тагын чыңлаган тавыш чыгарды.

Рәимов бер якка янтаеп Мостафаның җилкәсеә кулын салды.

Вәт шулай, М-Мо-Мостафа дус, – диде ул. – склад эше би-ик катлаулы эш. Күп вакыт за-за-коннарны да бо-боз-ар-га туры килә. Нишлисең бит, шунсыз яшәп булмый.

Ничек диләр әле, «закон нельзя нарушать, а можно обходить», – диде Мостафа, балык кочервасын түгә-түгә авызына якынлаштырып. – Шуның шикелле, син минекүрмә, мин сине. Ләкин, Мостафа кашык тоткан кулын хәрәкәтләндереп, – йөргән эзеңне күмә бел.

Рәимовны өйрәтергә түгел инде, ул һәр эшнең җаен белә, – ди җавапка Хәммәт.

Дефецит товарларны, он, дөге ярмасы, шикәр, конфет кебекләрне дә складтан ул дус-ишләргә шудырабыз да мөгәричен эчәбез. Ә магазиннарга счет-фактураны гына төртәсең.

Мостафа җанланып:

Җае табыла, мин андыйларны шома маташтырам, – дип дәртләнеп тагын стаканнарны чыңгылдатып алалар.

Мостафа складны ничек япканын хәтерләми. Хәтта почта урамына ничек килеп чыкканан да, юлда күпме вакыт аунап ятканын да хәтерләми. Күптән караңгыланган, өйләргә утлар алганнар иде. Ул янында сөйләшү тавышларын чак кына ишеткәнсыман, – бу яз көне исереп егылу ничек начар.

Әгәр ул пычракта тагын да аунаган булса, бәлки аны шул бала-чагалар өенә дә илтү чарасын күргән булырлар иде. Хәзер аны озату түгел, янына килергә дә куркалар, өстәвенә аның кем икәнен дә танымаслык. Ничек таысыннар, аның бите язгы апараланган балчык белән капланган.

Бераз аңына килгәнсыман булгач, Мостафа торып баскан иде, шунда ук гөпелдәп ауды… Аяклары ничек көчсезләр. Өстәвенә пычракка чумган кием дә авыр. Мостафа ныграк басарга, гәүдәсен турырак тотарга тырышты. Кая инде гәүдәне тигез алып бару, ул, җилле көндәге арыш сабагы шикелле чайкалды, аяклары чамашып сөрлекте һәм башы белән җиргә ауды.

«..Юк, Мостафаны исертергә әле… мин исерек т-тү-гел, бераз аяклар гына хәлсезләр. Менә, менә мин ничек туры барам, хәзер өй-гә кай-там. Хатынга да эчкәнемне әйтмим. Тукта әле сизмәсен. Бу хатын дигән нәрсә, бераз каптыңмы, бәй-бәйләнер-гә генә тора», – дип сөй-ләнә-сөйләнә атлады ул.

Өенә кайтасы урынга ул ничектер военкомат артындагы чокырга килеп чыкты. «Ох-хо-хо, мин кая килеп чыктым. Елгамы бу? Ю-ю-к, тү-гел, диңгез бу, диңгез, вот и да-даа. Ничего, исереккә диңгез тубыктан диләр, бу мин үтә алмаслык түгелдер». Мостафа лыпылдатып китереп басты, бер атлады, ике, су пычтырдап битенә чәчрәде, аягына үтте.

«Стоп, Мостафа. Исерек дигән белән мин җүләр түгеллә. Күрәләтә диңгезгә кереп батып үләргәмени миңа. Диңгез тубыктан булып батып үл имеш. Ю-юк, мин исерек түгел, аны гына аерырлак аңым бар».

Мостафа дүрт аякланып кире борылып чыкты да, өстен чишенеп ташлады һәм суга «сикерде» һәм…

«Вот так, вот шулай… Таки чыктым бит. Уф, пр-р-р… Диңгезне чүп тә итми йөзеп чыктым, вот кем ул Мостафа. Күлмәкне салмагач та йөзеп чыга алдым, кальсонны да салмасам да йөзә алган булыр идем…».

У-у-у, раз-б-о-о-й-й! Үләм… у-у-у, – дигән тавыш авылны яңгырата.

Кешеләр йокыдан уянды.

«Кемне талыйлар, кем бу! Моңа ошошлы хәл авыл тарихында да булганы юк лабаса».

Ләкин ярдәмгәчыккан ихтирамлы кешеләр куркышып кире өйләренә ашыктылар һәм ишекләрен ныклап бикләделәр. Бу Мостафа иде.

У-у-у… раз-боoo-й-й… Үлә-ә-әм…

«Ай салкын да соң төн. Әһм, кайтып җиттем ахыры, бу ишектер. Ну, бу хатынны, каршы чыкмаганы өчен…» ул шулай берничә өйнең тәрәзәсен төртте, пыялалар чылтырап төште һәм үзе дә җиргә ауды. Яңадан көч хәл белән бер тәрәзәгә барып ябышты, ниһаять, Мостафа бөтен көче белән этеп җибәрүгә тәрәзә пыялалары чалтырап төште. Ул үзе ачкан шушы «ишектән» өйгә кереп ауды.

Ник ачмадың! – дип могырдады яткан җиреннән. Мостафа як-ягына карады, ни күрсен, барысы да шәрә кешене күреп куркышып читкә посканнар, ә хатыны юк, чөнки бу үз өе түгел иде.

Менә шуның белән Мостафаның бу сяхәте тәмам булды. Ә Мостафаның стакан дустының сәяхәте ничегрәк тәмамлануын язып тормыйм, ул үзе сөйләр.

### Каенана һәм килен

Рәхимова Фәүзияне больницага салдылар. Аның кайчандыр алсуланып торган түгәрәк йөзе саргайган, озынчаланып калган, күзләре моңсуланганнар.

Ул төн буена кызышып, саташып ятты. Әле кайчан гына бит, җир тетрәтеп йөри торган кыз иде. Шәриф абый белән Хәдичә апаның сигез балаларыннан бер үзе калган бердәнбер кызлары иде. Фәүзия бик кадердә үсте, ләкин эшчән иде, һәр эшне дә җиренә җиткереп эшләүчән булды.

Килен булгач та сынатмады, җаны-тәне белән бирелеп эшләде. МТСта мотористка булып эшләгән вакытларында алган акчасының бер тиенен дә үзе туздырмый, тулысынча йортка кайтарып бирә иде. Ире Җәүдәткә генә түгел, каенанасы Нәкыяга да, каенатасы Хәммәтситдыйкка да ошарга тырышты ул.

Шулай матур гына эшләп йөргәндә, Фәүзиянең үпкәсенә салкын тиде. Менә инде икенче ел, ул үпкә авыруы белән җафалана.

Фәүзия авырый башлау белән, тормыш та үзгәрде. Болай да зәһәр каенана тагын да усалланды. Бервакыт табын янында утырганда Җәүдәт Фәүзияне ашарга кыстап, аңа берничә иркәле сүз әйткән иде. Бу исә Нәкыяга ошамады.

Нигә кыстап утырасың? Кунакка чакырмадым бит, – дип кычкырды ул.

Үткән ел Фәүзия бик авыр хәлдә больницада ятты. Авыру кешенең күңеле нечкә була, диләр. Фәүзия дә ишек ачылган саен ире Җәүдәтнең хәл белергә килүен көтте. Ике яшьлек кызы Айсылуны да өзелеп сагынды ул. Шулай бер көн үтте, ике, өч… Ләкин Җәүдәт күренмәде.

Бераз сәламәтләнгәч, Фәүзия ирен чакыртты, үзен килеп алырга кушты. Ләкин килүче булмады. юк хәлен баритеп, Фәүзия үзе кайтырга чыкты.

Әнкәй, – диде ул каенанасы янына кайткач, – миңа җылы сөт эчәргә куштылар… Ләкин ул сүзен дә әйтеп бетерә алмады, Нәкыя аны элеп алды.

Әгәр дә сөтне син генә эчеп торсаң, май, катык нәрсәдән ясарбыз, – диде ул кырыс кына.

Менә Фәүзия тагын больницада. Ул саргайган кулларына карады. Бәрәңге бакчасы казыганда кабарган хәлсез кулларын врачларга күрсәтергә курка иде ул.

Ярты ай чамасы дәвалангач, Фәүзия бераз сәламәтләнде һәм әнисе Хәдичәнең ярдәме белән Бидәңгенә кайтты..

Әңкәй, миңа санаториягә барырга кушалар, – диде ул.

Санаториягә түгел, җәһәннәмгә китсәң дә, терелә алмыйсың инде. Дәвалап була торган авыру түгел, – дип кычкырды Нәкыя.

Өйдә тавыш купты. Кызы белән килгән Хәдичә апага ял итәргә дә, чәй эчәргә дә тәкъдим итүче булмады. Ул күршегә кереп йоклады да, иртәгәсен кире Тарханга кайтып китте.

Бер көнне Җәүдәтне әнисе чакырып алды да:

Шул чахотка белән гомереңне әрәм итмә, – диде.

Өченчегә өйләнимме инде? – диде Җәүдәт. Нәкыягә исә бу бик гади тоелды.

Өченчегә булса ни, кызларбелән хәзер дөнья тулган, – диде ул.

Берничә көннән соң Фәүзиянең әтисе Шәриф абый Бидәңгегә килде.

Әйдә, кызым, киен. Җыназага бик тиз менәрсең, монда торсаң, – диде ул һәм Фәүзиянең әйберләрен арбага төйи башлады.

Алар капкадан чыгып барганда, Фәүзиянең кызы Айсылу әнисенең муенына сарылды.

Әнкәй, әнкәем, мин дә китәм. Мине дә калдырма, мин дә… Фәүзиянең күзләреннән яшьләр тәгәрәде. Үксеп-үксеп елаган баласын юатырга тырышты ул.

Елама, кызым… Санаториядән кайткач…

Арба кузгалып китте.

Совет иле Фәүзияне авыр хәлдә ташлап калдырмады. Аңа түләүчез путевка бирелде. Берничә көннән соң аны «Каменко» санаториясенә озаттылар.

Фәүзия дәваланыр һәм сәламәтләнеп кайтыр, әлбәттә. Ти Нәкыя белән Җәүдәт күңелендәге шәфкатьсезлекне дә бетерү чараларын табасы иде.

## Ялгышу

### I

Зөфәрнең күзләренә йокы кермәде. Ул чалкан да ятып карады, йөзтүбән дә, аннары одеалын бер якка кайтарып, уң ягына әйләнде.

Аның күз алдына кабат Сәрия белән кыйммәтле костюм кигән озын буйлы, киң җилкәле егет килде. Зөфәрнең тешләре кысылды. «Ә мин ничек ышанган идем аңа. Аның белән булачак тормыш турында хыяллана идем. Барысы да югалды… Менә бит кызлар ничек алдыйлар! Атна саен хат алганын сизгәч, шикләнгән идем шул, дөрес булган икән.

Бу абыемның хаты, яки бу бергә укыган иптәшемнең хаты дия иде тагын».

Зөфәр кроватеннән аякларын салындырып, торып утырды һәм ике кулы белән чәчен йомарлады. «Бу егет нинди чиста кингән, муенында галстук. Мөгаен ул я инженер, я булмаса укытучыдыр. Ә мин, мин шофер, өстемнән бензин исе аңкып тора.

Сәрия үзе дә аны бик ярата ахры. Кичә ничек култыклашып сөйләшеп баралар иде».

Зөфәр стенадагы зур сәгатькә күз салды һәм пошынып:

Тизрәк таң да атмый, ичмасам, – дип куйды ул һәм тагын уйга чумды…

Урак вакыты иде. Зөфәр машинасы белә ындыр табагына килеп җитеп кабинадан чыккан гына иде, аның каршысына кыска җиңле күлмәк кигән, озынрак буйлы кыз килеп басты. Аның йөзе һәм куллары тузанланган иде.

Машинагызны бераз читкәрәк алмассызмы икән? – диде ул ягымлы тавыш беән.

Зйфәр ни әйтергә белмичә бераз хәрәкәтсез торганнан соң:

Ә.. мин хәзер, – диде дә аерым бер җитезлек белән кабинага креп педальгә басты.

Ягез әле, тиз генә төяп алыйк, – диде Сәрия бодай тутырылган җитен капчыкның авызын тотып.

Бу рейстан Зөфәр тагын да кызурак әйләнеп кайтты. Ул инде бу кызның авылга укытучы булып килгәнен белергә дә өлгергән иде. Аның бу кайтуында Сәриянең кулында газета иде.

Әгәр син бүген кичәгегә караганда егерме центнерга артыграк илтсәң, – диде Сәрия елмаеп, – районыбызда иң алдынгы булган шофер Кадриевны куып җитәсең.

Зөфәрнең йөрәгендә ялкын кабынгандай булды.

Узам мин аны! – диде ул рухланып.

Менә шул көннән башлап Зйфәрнең тынычлыгы бөтенләй бозылды. Ул Сәрияне бер дә исеннән чыгармады. Аның саф, нечкә тавышы Зөфәрнең колагында яңгырыйдыр шикелле тоелды.

# Конец ознакомительного фрагмента.

Текст предоставлен ООО «ЛитРес».

Прочитайте эту книгу целиком, купив полную легальную версию на ЛитРес.

Безопасно оплатить книгу можно банковской картой Visa, MasterCard, Maestro, со счета мобильного телефона, с платежного терминала, в салоне МТС или Связной, через PayPal, WebMoney, Яндекс.Деньги, QIWI Кошелек, бонусными картами или другим удобным Вам способом.